Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

20 сентябрь, 2019 ел № 13

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитетынын «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 11 апрелендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1999 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе нотариаты турында 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» (2016 елның 11 апрелендәге 9 номерлы, 2019 елның 26 апрелендәге 8 номерлы карарларга үзгәрешләр белән) 2016 елның 11 апрелендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымта № 1дә:

- исемендә һәм текстында «васыятьнамәләр таныклыгы буенча һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
- «ышаныч язуы буенча» сүзләрен исемдә һәм текстта «күчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышанычнамә таныклыгы буенча» сүзләренә тиешле килешләрдә алмаштырырга;
- 1.4 пунктында 2 абзацны төшереп калдырырга;
- 2.10 пунктының 5 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.2. 6 нчы кушымтаның 1.5 пунктының 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татар Казысы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Г. Кәримуллин